ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.09.2019 п.г.т.Алексеевское № 434

**“Алексеевскмуниципаль районы**
**Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы**
**тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең**
**административ регламентларын раслау турында”**
**Алексеевскмуниципаль районы башкарма комитетының**
**3 сентябрь, 2018 ел, 275 нче карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

“Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәп турында»гы 2019 ел, 1 апрель, 48-ФЗ санлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль закон гамәлгә керү уңаеннан

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2018 ел, 3 сентябрь, 275 нчекарары белән муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 10 нчы кушымтасында»:

2 нче пунктның 2.6 нчы пунктчасында китерелгән "Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар исемлеге, хезмәт алучыларның категориясенә карап, 3 нче кушымтада китерелгән” дигән сүзләрне “Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең шәхси лицевой счетының (Россия Федерациясе Пенсия фондында) иминият номеры турында мәгълүматлар, шулай ук хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның категориясенә карап, 3 нче кушымта нигезендә документлар һәм мәгълүматлар алына», дигән сүзләргә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Алексеевск муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**